МИНИСТЕРСТВО ОБРАЗОВАНИЯ И НАУКИ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МӘГАРИФ ҺӘМ ФӘН МИНИСТРЛЫГЫ

**ПРИКАЗ** **БОЕРЫК**

14.10.2019 г. Казань № под-1451/19

Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгының «Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгының ведомство бүләкләре турында» 2017 елның 19 апрелендәге под-678/17 номерлы боерыгы белән расланган Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгының ведомство бүләкләре турында нигезләмәгә үзгәреш кертү хакында

Б о е р ы к б и р ә м:

1. Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгының «Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгының ведомство бүләкләре турында» 2017 елның 19 апрелендәге под-678/17 номерлы боерыгы (2017 елның 2 октябрендәге под-1572/17 номерлы, 2018 елның 29 августындагы под-1253/18 номерлы боерыклар нигезендә кертелгән үзгәрешләре белән) белән расланган Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгының ведомство бүләкләре турында нигезләмәгә түбәндәге үзгәрешне кертергә:

II нче бүлек. «Ведомство бүләге белән бүләкләүгә тәкъдим итү нигезләре»нә түбәндәге эчтәлекле 2.3 пунктын өстәргә:

«2.3. Бүләкнең һәр төре буенча бүләкләүгә тәкъдим ителә торган затлар саны:

гомуми штат саны 100 кешедән кимрәк булган оешмадан (органнан) елына бер кешедән артык булмаска;

гомуми штат саны 100 кешедән артык булган оешмалар (органнар) өчен һәр 100 эшләүче (хезмәткәр) арасыннан кимендә бер кешедән артык булмаска тиеш.».

2. Кадрлар сәясәте бүлегенә (Л.С.Әмирова) боерыкны имзалаганнан соң эш көннәрендә исәпләнгән өч көнлек срокта аны Татарстан Республикасы Юстиция министрлыгына дәүләт теркәвенә алу өчен җибәрергә.

3. Әлеге боерык үтәлешен контрольдә тоту буенча үземне җаваплы итеп билгелим.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры урынбасары – министр Р.Т.Борһанов